# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Хезмәт хакының минималь күләме турында

1 статья. 1993 елның 1 июленнән хезмәт хакының минималь күләмен аена 9000 сум дип билгеләргә.

Хезмәт хакының минималь күләменә өстәмә түләүләр һәм өстәлмәләр, шулай ук премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре керми.

2 статья. 1993 елның 1 июленнән бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләр өчен Уртак тариф челтәрендәге айлык тариф ставкасының /окладының/ I разряды 7740 сум күләмендә дип билгеләргә.

3 статья. Татарстан Республикасында салымнар турындагы гамәлдә булган законнар нигезендә түләнүче салымнарны, җыемнарны һәм башка түләүләрне исәпләү, хезмәт хакының минималь күләменә бәйле рәвештә, хезмәт хакының әлеге Законның 1 статьясында билгеләнгән минималь күләменнән чыгып башкарыла.

4 статья. "Татарстан Республикасында хезмәт хакының минималь күләме турында" Татарстан Республикасының 1993 елның 23 мартындагы Законы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның 15 июле
№ 1930-XII